**Иске Юраш урта мәктәбеннән**
**Бөек Ватан сугышында катнашкан якташ**
**укытучылар**



**Тарасов Дмитрий Григорьевич**
**1924 – 03.05.2007.**

Алабуга районы Иске Үтәгән авылында туган.
Курск дугасы, Көнбатыш Украина, Ленинград фронтларында катнаша.
Өченче дәрәҗә сугышчан дан ордены кавалеры.
1946-1950 нче елларда Алабуга педагогия училищесында белем ала.
1955нче елдан Иске Юраш мәктәбендә 33 елын балаларга тәрбия-белем бирүгә багышлый,математика фәнен укыта.Тирән белемле,таләпчән укытучы буларак, ул авылда бик зур абруй казана.



**Вәлиев Мирзаян Вәли улы**
**1918-20.05.1998**

Алабуга районы Иске Юраш авылында туган.
1939-1947нче елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.1945нче елда 561-Байкал арты хәрби округы составында японнарга каршы сугышта катнаша.1947 нче елда Иске Юраш җидееллык мәктәбендә биология укыта башлый.1961-1964 нче елларда Казан дәүләт педагогия институтында укый. 1956-1966 нчы елларда Иске Юраш урта мәктәбендә директор булып эшли.1978 нче елга кадәр география фәнен укыта



**Сабиров Тимерхан Сабир улы**
**1918-1998**

Алабуга районы Иске Юраш авылында крестьян гаиләсендә туган.Сугышка кадәр Юраш авылында белем ала һәм шунда эшли.1942 елда Бөек ватан сугышына алына.Сугыштан кайткач Иске Юраш урта мәктәбендә озак еллар тарих фәнен уктыта.Сугышта күрсәткән батырлыклары һәм педагогик эшчәнлеге өчен сугыш һәм хезмәт ветераны дигән исемгә лаек була. Бөек Ватан сугышында батырлык күрсәткән өчен Кызыл Йолдыз Ордены, Ватан Сугышы Ордены медальләре белән бүләкләнә.